Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLI-1**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 1 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге XI-1 номерлы, 2017 елның 24 июлендәге XX-1 номерлы, 2018 елның 12 апрелендәге XXX-1 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карарны гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3.Карарны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар. 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсенең 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсенең 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2019 елның
1 апрелендәге XLI-1 номерлы
карарына кушымта №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлеше 17 пунктын ",планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәгән булуы турында хәбәрнамә, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортының тиңдәшле торак пунктлар арасында урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яисә килмәве хакында хәбәрнамә җибәрү, Россия Федерациясе гражданнар законнары нигезендә торак пунктлар арасындагы территориядә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән тәртипләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм торак пунктлар территориядә урнашкан җир кишәрлеген кире алу, торак пунктлар арасындагы территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән тәртипләргә туры китерүне гамәлгә ашыру турында карар кабул итү" сүзләре белән тулыландырырга;

2) 7 маддәнең 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт белән тулыландырырга: "13) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 2300-1 номерлы Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны гамәлгә ашыру";

3) 8 маддәнең 1 өлеше 13 пунктын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: "планлаштырыла торган төзелеш яки индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортын реконструкцияләү (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә җибәрү, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль

торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәгән булуы турында хәбәрнамә, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яисә килмәве хакында хәбәрнамә,Россия Федерациясе гражданнар законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән каралтыны җимерү турында яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре, территорияләрне планировкалау документацияләре яки капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнар тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри таләпләр (алга таба шулай ук – билгеләнгән таләпләр белән тәңгәллеккә китерү) белән туры китерү турында, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылманны җимерүне гамәлгә ашыру яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләр белән тәңгәллеккә китерү”;

4) 17 маддәнең 2 өлешендә “муниципаль берәмлек башлыгының” сүзләрен “муниципаль берәмлек башлыгының яисә үзенең вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы җирле хакимият башлыгының,” сүзләренә алмаштырырга;

5) 27 маддәнең 7 өлеше 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы кәсәбәчелек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерциячел булмаган (Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси фирка, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз идарәсендә катнашудан, башка бер җәмәгать оешмасының, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек ияләре ширкәтләренең гомуми җыелышында яки корылтаенда (конференциясендә) катнашудан гайре) оешма белән идарә итүдә катнашырга, Россия Федерациясе Президенты акты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы оештыручы (гамәлгә куючы) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итүдән, федераль законнар белән каралган башка очраклар тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып муниципаль берәмлек торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итүдән тыш”;

6)39 маддәнең 4 өлеше 1 пунктында “федераль законнарда каралган очраклардан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә исеменнән оешма белән идарә итүдә катнашу очракларыннан” сүзләрен “Россия Федерациясе Президенты акты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы оештыручы (гамәлгә куючы) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итүдән, федераль законнар белән каралган башка очраклар тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып муниципаль берәмлек торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итүдән; федераль законнарда каралган бүтән очраклардан” сүзләренә алмаштырырга;

7)42 маддәнең 8 өлеше 1 пунктында “федераль законнарда каралган очраклардан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән оешма белән идарә итүдә катнашу очракларыннан” сүзләрен “Россия Федерациясе Президенты акты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы оештыручы (гамәлгә куючы) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итүдән, федераль законнар белән каралган башка очраклар тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып муниципаль берәмлек торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итүдән; федераль законнарда каралган бүтән очраклардан” сүзләренә алмаштырырга;

8) 46 маддәдә::

а)1 өлешнең 3 пункты өченче абзацын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

“,планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителгән булуы турында хәбәрнамә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителгән булмавы турында хәбәрнамә, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортының тиңдәшле торак пунктлар арасында урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йортын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яисә килмәве хакында хәбәрнамә җибәрә, Россия Федерациясе гражданнар законнары нигезендә торак пунктлар

арасындагы территориядә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яки аны билгеләнгән тәртипләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм торак пунктлар арасындагы территориядә урнашкан җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итә, торак пунктлар арасындагы территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән тәртипләргә туры китерүне гамәлгә ашыра";

б) 2 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 13 пункты белән тулыландырырга:

"13) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 2300-1 номерлы Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны гамәлгә ашыра.";

в) 3 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 15.1 пункты белән тулыландырырга:

"15.1) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын планлаштырыла торган төзү яки реконструкцияләү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгәннәрнең билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруга юл куелуы (рөхсәт ителүе) хакында хәбәрнамә, планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруга юл куелмавы (рөхсәт ителмәве) хакында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җирлекләр территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзегәндә яки реконструкцияләгәндә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки килмәве хакында хәбәрнамә җибәрә, Россия Федерациясенең гражданнар законнары нигезендә үзирекле (рөхсәтсез) төзелгән корылманы җимерү турында карар, үзирекле (рөхсәтсез) төзелгән корылманы җимерү (сүтү) яки аны җирдән файдалануның һәм төзелеш алып баруның билгеләнгән кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документация яки капиталь төзелеш объектлары параметрларына федераль законнар тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри таләпләр белән рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларына туры китерү (алга таба шулай ук – билгеләнгән таләпләр белән тәңгәллеккә китерү) турында карар, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген кулланудан алу турында карар кабул итә, үз белдегенчә (рөхсәтсез) төзелгән корылманы җимерүне яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күздә тотылган очраклардагы таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра".